| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**БОЕРЫК**

17.01.2023 Казан ш. № 3-од

Татарстан Республикасында
«Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез»
шәҗәрә фестивале турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары нигезендә,

Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестиваленең (алга таба – Фестиваль) бишьеллык юбилеен бәйрәм итү кысаларында

боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивале турында нигезләмәне расларга.

2. Архив документларын фәнни файдалану һәм халыкара элемтәләр бүлегенә:

- эшче төркем төзергә;
- җаваплы башкаручыларны билгеләргә;
- Фестивальне оештыру һәм үткәрүнең чаралар планын («юл картасын») әзерләргә;
- Фестивальне расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә оештырырга һәм үткәрергә.

3. Финанс-икътисад бүлегенә Фестивальдә җиңүчеләргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган максатчан чаралар хисабына акча түләүне гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез»

шәҗәрә фестивале турында» 2022 елның 7 февралендәге 8-од номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г. З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының елның 17.01.2023
3-од номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү турында**
**нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестиваленең (алга таба – Фестиваль, бәйге) максатларын һәм бурычларын, аны үткәрү тәртибен, эчтәлеген, катнашучыларына карата таләпләрне билгели.

1.2. Фестиваль Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган 2016 – 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерүнең дәүләт программасына кушымтаның 1.4.7 пункты нигезендә үткәрелә.

1.3. Фестивальне оештыручылар – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе.

2. Максат һәм бурычлар

2.1. Фестивальне үткәрүнең төп максатлары һәм бурычлары:

- буыннар алмашын саклап калу, милли гореф-гадәтләрнең һәм эстетик идеалларның бергәлеге нигезендә гаилә һәм гаилә-туганлык элемтәләрен ныгыту;
- үз нәселе, халкы, туган як тарихын өйрәнү;
- Татарстан Республикасы халыкларының милли традицияләрен, гореф-гадәтләрен торгызу;
- гаилә иҗаты традицияләрен яклау һәм үстерү, яшь буынга эстетик, әхлакый һәм рухи тәрбия бирүдә аның ролен көчәйтү.

3. Фестивальне оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Фестивальне үткәрү тәртибе, сроклары, шартлары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына (http://arhiv.tatarstan.ru) документлар кабул итеә башлаганчы кимендә 14 көн алдан урнаштырыла.

3.2. Фестивальдә катнашуга гариза биргән Фестивальдә катнашучы оештыру комитетына бирелгән белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен җаваплы була.

3.3. Фестиваль 3 этапта уздырыла: муниципаль, зона һәм республика этаплары, аларда катнашучыларны сайлап алу була.

3.4. Фестивальне әзерләү һәм уздыру өчен оештыру комитеты төзелә.

3.5. Оештыру комитеты:

- Фестивальне турыдан-туры үткәрүне тәэмин итә;

- Фестивальнең жюри карарын беркетмә белән рәсмиләштерә;

- Фестивальне әзерләү һәм үткәрү эшләрен координацияләүне гамәлгә ашыра;

- оештыру мәсьәләләрен хәл итә;

- әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Оператив мәсьәләләрне хәл итү өчен оештыру комитеты эшче төркемнәр төзергә хокуклы.

3.6. Фестивальдәге жюри (алга таба – жюри):

- Фестивальдә катнашучылар тарафыннан биремнәрне һәм башка төр сынауларны үтәү нәтиҗәләрен тикшерә һәм бәяли;

- Фестиваль җиңүчеләре, призерлары кандидатураларын билгели.

3.7.1. Фестивальдә яшь ягыннан чикләүләр булмаган, милләте һәм дине нинди булуга карамастан, берничә буынны берләштергән гаилә-туганнар төркемендә катнашучылардан гыйбарәт гаилә коллективлары (гаилә-туганнар төркемнәре) (кимендә өч кеше, катнашучыларның максималь саны чикләнми) катнаша.

3.7.2. Авыл җирлекләре, муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмалары Фестивальнең муниципаль этабына катнашу өчен гаилә коллективларын тәкъдим итә алалар.

3.8. Фестивальдә катнашу өчен гариза бирүчеләр Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына кәгазь яки электрон рәвештә гариза бирәләр. Гариза Татарстан Республикасының Архив эше буенча Дәүләт комитетына кергән көнне теркәлергә тиеш.

Гаризаларны кабул итү даталары Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана, ул «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына (http://arhiv.tatarstan.ru) бәйге эшләре кабул ителә башлаганчы кимендә ун календарь көн алдан урнаштырыла.

Фестивальдә катнашу өчен гариза бирүчеләр Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына түбәндәге документларны тапшыралар:

а) әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган форма буенча фестивальдә катнашуга анкета-гариза;

б) гаилә коллективы вәкиленең шәхесен раслый торган документының күчермәсе;

в) гаилә-туганнар төркеменең шәҗәрәсе;

г) Фестивальдә катнашырга планлаштырган гаилә-туганнар төркеменең һәр әгъзасыннан шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык ( әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта);

д) шәхси мәгълүматлар субъекты таратырга рөхсәт биргән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә Фестивальдә катнашырга планлаштырган гаилә-туганнар төркеменең һәр әгъзасыннан ризалык (әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта);

е) Фестивальдә катнашуы планлаштырылган балигъ булмаган баланың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә аның законлы вәкиле тарафыннан рәсмиләштерелгән ризалык (әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымта);

ж) шәхси мәгълүматлар субъекты таратырга рөхсәт биргән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә Фестивальдә катнашуы планлаштырылган балигъ булмаган баланың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә аның законлы вәкиле тарафыннан рәсмиләштерелгән ризалык.

3.9. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тапшырылган документларны, шулай ук гаилә-туганнар төркемнең шәҗәрәләрендә бирелгән мәгълүматның дөреслеген тикшерүне 10 февральгә кадәр үткәрә.

Гариза бирүчене фестивальдә катнашуга кертүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган документларны гаризага кушып тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

гаризаны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтында күрсәтелгән срокны бозып тапшыру;

гаилә-туганнар төркеме шәҗәрәсендә хаталар булу (тексттагы хаталар, туган көннәрендәге ялгышлар).

Гариза бирүчеләргә Фестивальдә катнашуга кертелмәү турында карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә бу хакта электрон почта яки телефон элемтәсе аша хәбәр итәлә.

Фестивальдә катнашуга кертелмәгән гариза бирүчеләр кимчелекләрне бетергәннән соң, гаризаларны тапшыру өчен билгеләнгән срокта кабат Фестивальдә катнашуга гариза тапшыра алалар.

Фестивальдә катнашу өчен гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң килгән гаризалар каралмый.

## 4. Фестивальнең муниципаль этабын үткәрүнең төп шартлары һәм тәртибе

4.1. 1 этап – муниципаль этап – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә муниципаль этап үткәрелә торган муниципаль берәмлекләрнең җитәкчеләре белән алдан килешенгән график буенча 20 февральдән алып 10 мартка кадәр чорда үткәрелә.

4.2. Фестивальнең муниципаль этабы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә үткәрелә.

4.3. Фестивальнең муниципаль этабын үткәрү тәртибе:

4.3.1. Фестивальнең муниципаль этабы программасы 2 блокны үз эченә ала, аларны расланган критерийлар буенча (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган) жюри әгъзалары бәяли:

1) әзерләнгән милли һәм гаилә ризыклары күргәзмәсе (камыр ризыгы, традицион һәм махсус ризыклар), регламент 3 минуттан озак түгел;

2) «Таныш булыгыз, минем гаиләм, минем нәселем!» гаилә командалары конкурсы – шәҗәрә презентациясе белән бергә матур концерт номерын үз эченә алган команданың визит карточкасы. Номерның куелу рәвеше ирекле: бию, җыр, театральләштерелгән тамаша һ.б., гаилә милли костюмы да күрсәтелергә мөмкин. Регламент 7 минуттан озак түгел.

Регламент бер командага 10 минуттан озак түгел.

4.3.2. Гаиләнең генеалогик агачы (шәҗәрә) гаилә династияләрен аңлатудан, ядкәрләр һәм коллекцияләр турындагы материаллардан, гаилә тормышындагы кызыклы фактлардан (гаилә риваятьләре) гыйбарәт булырга һәм, альбом, стенд, панно, баннер-коллаж һ.б. рәвешендә бизәлгән булып, тәкъдим ителгән шәҗәрәнең текст нигезләвен дә үз эченә алырга тиеш. Шәҗәрәне расланган критерийлар буенча (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган) жюри әгъзалары бәяли:

4.4.3. Массакүләм мәгълүмат чараларында Фестивальне яктырту оештырыла, район һәм шәһәр басма матбугатында тәкъдим ителгән шәҗәрәләр бастырыла.

4.4. Фестивальнең муниципаль этабында беренче урынны алган катнашучылар Фестивальнең зона этабына җибәрелә.

## 5. Фестивальнең зона этабын үткәрүнең төп шартлары һәм тәртибе

5.1. 2 этап – зона этабы – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә зона этабы уза торган муниципаль берәмлекләр җитәкчеләре белән алдан килештерелгән график буенча 4 апрельдән алып 12 апрельгә кадәр үткәрелә.

Фестивальнең зона этабы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә 6 зонага бүленгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә оештырыла һәм үткәрелә:

1 зона. Мөслим авылы (Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Мөслим, Сарман, Чирмешән, Ютазы муниципаль районнары);

2 зона. Зәй шәһәре (Әгерже, Актаныш, Зәй, Алабуга, Зәй, Менделеевск, Минзәлә, Түбән Кама, Тукай муниципаль районнары һәм Чаллы шәһәре);

3 зона. Әлки авылы (Аксубай, Алексеевск, Әлки, Лаеш, Яңа Чишмә, Нурлат, Балык Бистәсе, Спас, Чистай муниципаль районнары);

4 зона. Балтач шәһәр тибындагы поселогы (Арча, Әтнә, Балтач, Биектау, Кукмара, Мамадыш, Питрәч, Саба, Теләче муниципаль районнары);

5 зона. Иске Чүпрәле авылы (Апас, Буа, Югары Ослан, Чүпрәле, Зеленодольск, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш муниципаль районнары);

6 зона. Казан шәһәре – Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет районнары.

Фестивальне үткәрү зоналары (муниципаль берәмлекләр) ел саен күчә торган график буенча үзгәртелә.

5.2. Фестивальнең зона этабын үткәрү тәртибе.

5.2.1. Фестивальнең зона этабында әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән зоналарга кергән муниципаль берәмлектән муниципаль этапны узган бер гаилә коллективы (гаилә-туганнар төркеме) катнаша.

5.2.2. Фестивальнең зона этабы программасы ике блокны үз эченә ала, аларны расланган критерийлар буенча (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган) жюри әгъзалары бәяли:

1) әзерләнгән милли һәм гаилә ризыклары күргәзмәсе (камыр ризыгы, традицион һәм махсус ризыклар), регламент 3 минуттан озак түгел;

2) «Таныш булыгыз, минем гаиләм, минем нәселем!» гаилә командалары конкурсы – шәҗәрә презентациясе белән бергә матур концерт номерын үз эченә алган команданың визит карточкасы. Номерның куелу рәвеше ирекле: бию, җыр, театральләштерелгән тамаша һ.б., гаилә милли костюмы да күрсәтелергә мөмкин. Регламент 7 минуттан озак түгел.

Регламент бер командага 10 минуттан озак түгел.

5.2.3. Гаиләнең генеалогик агачы (шәҗәрә) гаилә династияләрен аңлатудан, ядкәрләр һәм коллекцияләр турындагы материаллардан, гаилә тормышындагы кызыклы фактлардан (гаилә риваятьләре) гыйбарәт булырга һәм, альбом, стенд, панно, баннер-коллаж һ.б. рәвешендә бизәлгән булып, тәкъдим ителгән шәҗәрәнең текст нигезләвен дә үз эченә алырга тиеш. Шәҗәрәне расланган критерийлар буенча (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган) жюри әгъзалары бәяли.

5.2.4. Массакүләм мәгълүмат чараларында Фестивальне яктырту оештырыла, район һәм шәһәр басма матбугатында тәкъдим ителгән шәҗәрәләр бастырыла.

5.3. Фестивальнең зона этабында беренче урынны алган катнашучылар Фестивальнең республика этабына җибәрелә.

## 6. Республика этабын үткәрүнең төп шартлары һәм тәртибе

6.1. 3 этап – республика этабы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан 15 апрельдән алып 15 майга кадәр үткәрелә.

Республика этабына йомгак 15 майда ясала.

6.2. Фестивальнең республика этабын үткәрү тәртибе.

6.2.1. Фестивальнең республика этабы программасы ике блокны үз эченә ала, аларны расланган критерийлар буенча (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган) жюри әгъзалары бәяли:

1) Әзерләнгән милли һәм гаилә ризыклары күргәзмәсе (камыр ризыгы, традицион һәм махсус ризыклар). Регламент 3 минуттан озак түгел;

2) «Таныш булыгыз, минем гаиләм, минем нәселем!» гаилә командалары конкурсы – шәҗәрә презентациясе белән бергә матур концерт номерын үз эченә алган команданың визит карточкасы. Номерның куелу рәвеше ирекле: бию, җыр,

театральләштерелгән тамаша һ. б., гаилә милли костюмы да күрсәтелергә мөмкин. Регламент 7 минуттан озак түгел.

Бер командага регламент 10 минуттан озак түгел.

6.2.2. Гаиләнең генеалогик агачы (шәҗәрә) гаилә династияләрен аңлатудан, ядкәрләр һәм коллекцияләр турындагы материаллардан, гаилә тормышындагы кызыклы фактлардан (гаилә риваятьләре) гыйбарәт булырга һәм, альбом, стенд, панно, баннер-коллаж һ.б. рәвешендә бизәлгән булып, тәкъдим ителгән шәҗәрәнең текст нигезләвен дә үз эченә алырга тиеш. Шәҗәрәне расланган критерийлар буенча (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган) жюри әгъзалары бәяли.

6.2.3. Массакүләм мәгълүмат чараларында Фестивальне яктырту оештырыла.

## 7. Җиңүчеләрне билгеләү, нәтиҗәләр чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү тәртибе

7.1. Муниципаль, зона һәм республика этабы призерлары (1, 2 һәм 3 урыннар) жюри тарафыннан беренче һәм икенче блокларның шәҗәрәләрне бәяләүдән алынган баллары суммасы буенча  билгеләнә. Иң күп балл исәбен җыйган өч гаилә коллетивы призерлар була.

7.2. Муниципаль этапның приз фонды муниципаль берәмлекнең хокукый акты белән билгеләнә.

7.3. Зона этабы призерлары (1, 2, 3 урыннар) дипломнар һәм акчалата бүләкләр белән түбәндәгечә бүләкләнә:

50 000 (илле мең) сум – I урын өчен

40 000 (кырык мең) сум – II урын өчен

30 000 (утыз мең) сум – III урын өчен.

7.4. Республика этабы призерлары (1, 2, 3 урыннар) дипломнар һәм акчалата бүләкләр белән түбәндәгечә бүләкләнә:

150 000 (йөз илле мең) сум – I урын өчен

130 000 (йөз утыз мең) сум – II урын өчен

100 000 (йөз мең) сум – III урын өчен.

7.5. Зона һәм республика этабы призерларына акчалата призлар банк реквизитларын биргән көннән алып 10 көн эчендә күчерелә.

## 8. Жюри

8.1. Гаилә коллективлары чыгышларын бәяләү максатыннан муниципаль, зона һәм республика этаблары өчен жюри составы төзелә.

8.2. Фестивальнең муниципаль этабы кысаларында катнашучыларның чыгышларын бәяләү өчен Татарстан Республикасының һәр муниципаль районына чыгу өчен Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан өчәр кешелек 6 жюри составы төзелә.

8.3. Фестивальнең зона этабы кысаларында катнашучыларның чыгышларын бәяләү өчен Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан 12 кешедән гыйбарәт жюри составы төзелә.

8.4. Республика этабына жюриның персональ составы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана. Жюри составына республика башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмалары, мәгариф учреждениеләре һәм фәнни җәмәгатьчелек вәкилләреннән гыйбарәт рәис, рәис урынбасары җитәкчелегендәге 15 кеше раслана.

8.5. Жюри эше белән рәис җитәкчелек итә. Ул булмаганда, вазыйфалар аның урынбасарына йөкләнә. Жюриның экспертларны өстәмә җәлеп итү хокукы була. Фестивальнең гаилә коллективлары чыгышларын бәяләү нәтиҗәләрендә шәхси мәнфәгатьләре булган затлар жюри әгъзалары була алмый.

8.6. Жюри эше аның утырышында башкарыла. Муниципаль этапта утырыш, әгәр анда жюриның барлык әгъзалары катнашса, хокуклы дип санала. Зона һәм республика этапларында утырыш, әгәр аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

8.7. Жюри эше түләүле була.

8.8. Жюри карары утырышта катнашучы әгъзаларының баллар белән бирелгән бәяләвенә нигезләнеп кабул ителә һәм тавыш бирелгән көнне үк утырышта катнашкан жюри әгъзалары һәм рәис тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Тигез баллар исәбен җыйган берничә катнашучы булганда, җиңүче тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышларның гади күпчелеге белән билгеләнә. Бирелгән тавышларның саны тигез булганда, жюри утырышында рәиснең тавышы хәлиткеч була.

## 9. Финанслау

9.1. Фестивальне финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2025 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Милли һәм гаилә ризыкларын бәяләү критерийлары

| № | **Критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| 1. | Тәкъдим итү (савыт-саба, бизәү өчен атрибутлар) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 2. | Әзерләүнең техник катлаулыгы | 0 алып 10 кадәр балл |
| 3. | Тәме | 0 алып 10 кадәр балл |
| 4. | Эстетик башкарылышы (тышкы кыяфәте, консистенциясе, төсе) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 5. | Милли декор элементларын куллану | юк – 0 балл;<br>әйе – 10 балл |
| 6. | Вакытны чикләү буенча регламентның үтәлүе | юк – 0 балл;<br>әйе – 10 балл |

Командаларның визит карточкаларын бәяләү критерийлары

| № | **Критерийлар** | **Баллар** |
|---|---|---|
| 1. | Җыр башкару (башкару сыйфаты, вокалга осталык, башкару катлаулылыгы) | 0 алып 5 кадәр балл |
| 2. | Бию номеры (номерның катлаулылыгы, башкару техникасы, биючеләр саны) | 0 алып 5 кадәр балл |
| 3. | Барлык гаилә әгъзаларының катнашуы | юк – 0 балл;<br>әйе - 5 балл |
| 4. | Аудиовизуаль мөмкинлекләр (аудиовизуаль рәтнең техник характеристикалары: сурәтнең сыйфаты, тавышның чисталыгы һ. б.) | 0 алып 5 кадәр балл |
| 5. | Сәнгать номеры (театральләштерү, пантомима һ. б.) | 0 алып 5 кадәр балл |
| 6. | Номерның оригинальлеге (гадәти булмаган алым) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 7. | Акробатик элементлар башкару (комбинацияләрнең катлаулылыгы, башкару | 0 алып 10 кадәр балл |

| | | |
|---|---|---|
| | техникасы) | |
| 8. | Музыка уен коралларын куллану | юк – 0 балл;<br>әйе – 10 балл |
| 9. | Техник чаралар яки декорацияләр куллану (дизайн, милли элементлар) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 10. | Артистлык (риторика, сәхнә осталыгы, импровизация күнекмәләре һ. б.) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 11. | Вакытны чикләү буенча регламентның үтәлүе | 0 алып 10 кадәр балл |
| **Шәҗәрәне презентацияләү** | | |
| 12. | Фотодокументлар булу | юк – 0 балл;<br>бар – 5 балл |
| 13. | Шәҗәрә төзүче турында мәгълүмат булу | юк – 0 балл;<br>бар – 5 балл |
| 14. | Генеалогик агач (шәҗәрә) төзү (туу, вафат булу датасы, кайсы катламга каравы, вазыйфасы, исеме турында язмалар, гаилә риваятьләре һ.б.) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 15. | Исемнәре һәм гамәлләре торак пунктларның, җирлекләрнең һәм башка объектларның атамаларына нигез итеп алынган кешеләр турында кыскача белешмәләрнең булуы | юк – 0 балл;<br>бар – 5 балл |
| 16. | Кешеләр, вакыйгаларның замандашлары белән бәйле булган тарихи вакыйгаларның кыскача тасвирламасы булу | юк – 0 балл;<br>бар – 5 балл |
| 17. | Шәҗәрәне җентекләп күрсәтү һәм аның тарихи (архив) белешмәләргә туры килүе | 0 алып 10 кадәр балл |
| 18. | Шәҗәрәне төзегәндә кулланыла торган архив һәм документаль чыганакларның күләме (гаилә, муниципаль һәм дәүләт архивлары документлары) | 0 алып 10 кадәр балл |
| 19. | Генеалогик туганлык терминнарын (ягъни субъектларның туганлык дәрәҗәсен билгели торган терминнар) дөрес куллану | 0 алып 10 кадәр балл |
| 20. | Шәҗәрәнең сәнгатьчә бизәлеше (оригинальлек, дизайн, иҗади якын килү һ. б.) | 0 алып 10 кадәр балл |
| **Гаилә милли киемен презентацияләү** | | |
| 21. | Гаилә костюмы булу | юк – 0 балл;<br>бар – 5 балл |
| 22. | Этник мотивлар булу | юк – 0 балл;<br>бар – 10 балл |
| 23. | Оригинальлек (образ гармониясе һәм күркәмлеге, костюмның сыйфаты, чигүле булу) | 0 алып 10 кадәр балл |

Ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

«Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез»
шәҗәрә фестивалендә катнашуга
**АНКЕТА-ГАРИЗА**

Анкета-гариза гаилә-туганнар төркеме вәкиле (алга таба – вәкил) тарафыннан тутырыла.

<table>
<tr><td>1.</td><td colspan="2">Гаилә коллективы (фамилия күрсәтелә)</td><td></td></tr>
<tr><td>2.</td><td colspan="2">Катнашу башкарылачак муниципаль берәмлек</td><td></td></tr>
<tr><td>3.</td><td colspan="2">Вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)</td><td></td></tr>
<tr><td>4.</td><td colspan="2">Вәкилнең яшәү урыны адресы</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="4">Вәкил белән элемтәгә чыгу өчен белешмәләр</td></tr>
<tr><td>5.</td><td colspan="2">Телефон</td><td></td></tr>
<tr><td>6.</td><td colspan="2">E-mail</td><td></td></tr>
<tr><td colspan="4">Гаилә коллективыннан башка зат белән элемтәгә чыгу өчен белешмәләр</td></tr>
<tr><td>7.</td><td colspan="2">Телефон</td><td></td></tr>
<tr><td>8.</td><td colspan="2">E-mail</td><td></td></tr>
<tr><td>9.</td><td colspan="3">Гаилә-туганнар төркеменнән Фестивальдә катнашачак затлар исемлеге (анкета-гаризага түбәндәге форма буенча кушып бирелә)</td></tr>
<tr><td></td><td>№</td><td>ФИАи (соңгысы – булган очракта)</td><td>Яше</td></tr>
</table>

Дата

Имза

Ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә рөхсәт

Мин ____________________________________________________________,
*Фестивальдә катнашучының ФИАи тулысынча (соңгысы – булган очракта)*
элемтә өчен телефоным: ______________________________________________
ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивале үткәрелү кысаларында Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына (алга таба – Оператор), «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында каралганча, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә үземнең шәхси мәгълүматларымны автоматлаштыру чараларын кулланып эшкәртүгә, Оператор сайтларында (http://arhiv.tatarstan.ru) казанышларым турында мәгълүмат урнаштыруга һәм Конкурс җиңүчеләре турында мәгълүмат урнаштыруга ризалык бирәм.

Моның белән Операторга шәхси мәгълүматларның түбәндә санап кителгән категорияләрен карый торган шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм:

1. ФИАи (соңгысы – булган очракта)
2. Элемтә өчен телефон
3. Социаль статус

Шәхси мәгълүматларымны бары тик түбәндәге максатларда файдалануга ризалык бирәм:

- Анкета-гариза төзү һәм эшкәртү;
- тапшырылган материалларны карау;
- статистика алып бару;
- Операторның рәсми сайтында фестиваль нәтиҗәләрен чыгару;
- югарыда күрсәтелгән максатлар белән бәйле башка гамәлләр.

Минем сурәтләрне ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивале үткәрелү кысаларында басма матбугатларда, интернет челтәрендә, радио- һәм телевизион эфирда урнаштырыла торган мәгълүмати һәм башка материалларда файдалануга ризалык бирәм.

Сурәтләрем минем намусыма, вөҗданыма һәм эшлекле абруема тап төшерә торган ысуллар белән файдалана алмый.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалык бирелгән вакытыннан алып вакыты чикләнмичә гамәлдә була һәм минем тарафтан, Операторга Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә гади язма рәвештәге гариза тапшырылып, кире алынырга мөмкин.

"___" _________, 20___ ел ______________________ ________________

(конкурста катнашучы имзасы) (фамилия, инициаллар)

Ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

Таратырга шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,_______________________________________________________________,
шәхси мәгълүматлар субъектының Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта) тулысынча

элемтә өчен телефон: ____________________, электрон почта адресы ___________________,

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясын нигез итеп алып, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына (алга таба – Оператор) ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү кысаларында Операторның рәсми сайтында (https://arhiv.tatarstan.ru/) минем хакта мәгълүмат урнаштыру максатларында минем шәхси мәгълүматларымны түбәндәге тәртиптә таратырга ризалык бирүем турында белдерәм:

| Шәхси мәгълүматлар категориясе | Шәхси мәгълүматлар исемлеге | Таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Чикләнмәгән затлар даирәсенә таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Шартлар һәм тыюлар | Өстәмә шартлар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | Фамилия | | | | |
| | Исем | | | | |
| | Атасының исеме | | | | |
| | Мәгариф оешмасы | | | | |
| | Социаль статус | | | | |
| Биометрик шәхси мәгълүматлар | Йөзнең төсле цифрлы фотография сурәте | | | | |

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматларыннан чикләнмәгән затлар даирәсе файдалана алачак һәм алар белән башка гамәлләр башкарылачак Операторның мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр:

| Мәгълүмат ресурсы | Шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр |
|---|---|
| http:// arhiv.tatarstan.ru | Чикләнмәгән затлар даирәсенә бирү |

Әлеге ризалыкны үз ихтыярым белән бирәм һәм «__» ________, 20__елдан алып « __» _________, 20__ елга кадәр гамәлдә була.

Шәхси мәгълүматларымны таратуны туктатуны таләп итү хокукы үземдә кала. Таләп куелган очракта, Оператор кичекмәстән минем шәхси мәгълүматларымны таратуны туктатырга, шулай ук шәхси мәгълүматлар тапшырылган өченче затлар исемлеген хәбәр итәргә тиеш.

______________ ______________________ ______________________
дата имза фамилия, инициаллар

Ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

## Балигъ булмаганның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык

Мин,____________________________________________________________________________,
шәхси мәгълүматлар субъекты ата-анасының (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

элемтә өчен телефон: ____________________,

______________________________________________________________ исеменнән эш итүче буларак,
(тәкъдим ителүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына

______________________________________________________________ шәхси мәгълүматларын
(тәкъдим ителүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү кысаларында автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштырылган эшкәртү чараларын кулланмыйча эшкәртүгә ризалык бирәм.

Әлеге рөхсәт тиешле мәгълүматны яки Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алган документларны саклау вакыты чыккан чорга кадәр бирелә.

"___" _________, 20___ ел ______________________ ________________

(законлы вәкил имзасы) (фамилия, инициаллар)

Ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү турында нигезләмәгә
6 нчы кушымта

Таратырга шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән балигъ булмаган баланың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык

Мин,________________________________________________________________,
шәхси мәгълүматлар субъекты ата-анасының (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

элемтә өчен телефон: ____________________________________________________,
______________________________________________________ исеменнән эш итүче буларак,
(тәкъдим ителүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясын нигез итеп алып, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына (алга таба – Оператор) ел саен уздырыла торган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивален үткәрү кысаларында Операторның рәсми сайтында (https://arhiv.tatarstan.ru/)
___________________________________________________________________________,
(тәкъдим ителүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

шәхси мәгълүматларын урнаштыру максатларында аларны түбәндәге тәртиптә таратырга ризалык бирүем турында белдерәм:

| Шәхси мәгълүматлар категориясе | Шәхси мәгълүматлар исемлеге | Таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Чикләнмәгән затлар даирәсенә таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Шартлар һәм тыюлар | Өстәмә шартлар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | Фамилия | | | | |
| | Исем | | | | |
| | Атасының исеме | | | | |
| | Мәгариф оешмасы | | | | |
| | Социаль статус | | | | |
| Биометрик шәхси мәгълүматлар | Йөзнең төсле цифрлы фотография сурәте | | | | |

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматларыннан чикләнмәгән затлар даирәсе файдалана алачак һәм алар белән башка гамәлләр башкарылачак Операторның мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр:

| Мәгълүмат ресурсы | Шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр |
|---|---|
| http:// arhiv.tatarstan.ru | Чикләнмәгән затлар даирәсенә бирү |

Әлеге ризалыкны үз ихтыярым белән бирәм һәм «__» ________, 20__елдан алып « __» _________, 20__ елга кадәр гамәлдә була.

Шәхси мәгълүматларны таратуны туктатуны таләп итү хокукы үземдә кала. Таләп куелган очракта, Оператор кичекмәстән минем шәхси мәгълүматларны таратуны туктатырга, шулай ук шәхси мәгълүматлар тапшырылган өченче затлар исемлеген хәбәр итәргә тиеш.

| __________ | _______________ | _______________ |
|---|---|---|
| дата | имза | фамилия, инициаллар |